Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Кибәк Иле авыл җирлеге Советы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Кибәк Иле авыл җирлеге башлыгы

КАРАРЫ

13 ноябрь, 2019 ел № 3

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кибәк Иле авыл җирлеге торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законының 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Питрәч муниципаль районы Кибәк Иле авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Кибәк Иле авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләргә:

Халык җыенын өч этапта уздырырга:

- гражданнар җыенының беренче этабы 2019 елның 26 ноябрендә 14 сәгать 00 минутта авыл мәдәният йорты бинасында, Тукай урамы, 28 нче йорт адресы буенча үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Тукай, Яшел урамнары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

- 2019 елның 30 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта авыл мәдәният йорты бинасында, Тукай урамы, 28 нче йорт адресы буенча халык җыенының икенче этабын үткәрергә. Җыенда катнашучылар исемлегенә Нариманов, Бакча урамнары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә.

- 2019 елның 7 декабрендә 13 сәгать 00 минутта авыл мәдәният йорты бинасында, Тукай урамы, 28 нче йорт адресы буенча халык җыенының өченче этабын үткәрергә. Җыенда катнашучылар исемлегенә Чишмә, Яңа, Мәктәп урамнары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез, 2020 елда Кибәк Иле авыл җирлеге Кибәк Иле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 төркем, эшләмәүче 2 төркем инвалидларны, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарын, көндезге уку формасы студентларын, 80 яшькә җиткән гражданнарны бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Кибәк Иле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Питрәч муниципаль районы
Кибәк Иле авыл җирлеге башлыгы И.М.Зиннуров